КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 28 август г.Казань № 709

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елның IV кварталында һәм 2019 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән клиника-лаборатория диагностикасы табиб-белгечләренә, табибларына Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары турында» 2014 ел, 25 февраль, 120 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елның IV кварталында һәм 2019 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән клиника-лаборатория диагностикасы табиб-белгечләренә, табибларына Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары турында» 2014 ел, 25 февраль, 120 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 5 август, 557 нче; 2018 ел, 15 сентябрь, 784 нче; 2019 ел, 18 март, 191 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2018 елның III – IV кварталларында һәм 2019 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән табиб-белгечләренә, клиника-лаборатория диагностикасы табибларына, фельдшерлык-

акушерлык пунктлары мөдирләренә – фельдшерларына, шулай ук фельдшерлык-акушерлык пунктлары патронаж фельдшерларына, акушерларына, шәфкать туташларына Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары турында»;

1 пунктта «2018 елның IV кварталында һәм 2019 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән» сүзләрен «, фельдшерлык-акушерлык пунктлары мөдире – фельдшерларга, шулай ук 2018 елның III-IV кварталларында һәм 2019 елда Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына караган Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән фельдшерлык – акушерлык пунктлары патронаж фельдшерларына, акушерларына, шәфкать туташларына» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта:

икенче абзацта «2018 елның IV кварталында һәм 2019 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән» сүзләрен «, фельдшерлык-акушерлык пунктлары мөдире – фельдшерларга, шулай ук 2018 елның III-IV кварталларында һәм 2019 елда Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына караган Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән фельдшерлык – акушерлык пунктлары патронаж фельдшерларына, акушерларына, шәфкать туташларына» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «2018 елның IV кварталында һәм 2019 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән» сүзләрен «, фельдшерлык-акушерлык пунктлары мөдире – фельдшерларга, шулай ук 2018 елның III-IV кварталларында һәм 2019 елда Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына караган Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән фельдшерлык – акушерлык пунктлары патронаж фельдшерларына, акушерларына, шәфкать туташларына» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктның өченче абзацында «һәм конкурс үткәрү тәртибе» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган 2018 елның IV кварталында һәм 2019 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән клиника-лаборатория диагностикасы табиб-белгечләренә, табибларына 2019 елда Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары бирү тәртибендә;

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2018 елның III – IV кварталларында һәм 2019 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән табиб-белгечләренә, клиника-лаборатория диагностикасы табибларына, фельдшерлык-акушерлык пунктлары мөдирләренә – фельдшерларына, шулай ук фельдшерлык-акушерлык пунктлары патронаж фельдшерларына, акушерларына, шәфкать

туташларына 2019 елда Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары бирү тәртибе»;

3 пунктта: «55 яше тулмаган» сүзләрен төшереп калдырырга;

алтынчы абзацта «өлеше» сүзләрен «пункты» сүзләренә алмаштырырга

5 пунктка түбәндәге эчтәлекле «е» пунктчасын өстәргә:

«е) Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүче (җыючы, иминият взносларын түләүче, салым агенты) салым, җыемнар, иминият взнослары, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычларны үтәү турында белешмә формасын раслау турында" 2017 елның 20 гыйнварындагы ММВ-7-8/20@ номерлы боерыгы белән билгеләнгән форма буенча белешмә».»;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Әлеге Тәртипнең 3 һәм 5 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килүкилмәүне тикшерү, конкурс комиссиясе утырышында карау өчен, Министрлык тарафыннан тапшырылган гаризаларны һәм документларны теркәгән көннән алып 30 көн эчендә башкарыла. Документларны теркәү документлар кабул итү көнендә башкарыла.»;

түбәндәге эчтәлекле 8[1] пункт өстәргә:

«8[1]. Әлеге Тәртипнең 8 пунктында каралган тикшерү белән бер үк вакытта Министрлык соратуны тиешле медицина оешмасына җибәрә, ул Министрлык соратуын алган көннән соң биш көн эчендә түбәндәге документларны тапшыра:

а) Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең «Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан сәламәтлек саклау өлкәсендә федераль статистик күзәтүне оештыру өчен статистик инструментарийны раслау турында» 2018 елның 3 августындагы 483 номерлы боерыгы белән расланган «Медицина оешмасы турында мәгълүматлар" № 30 федераль статистик күзәтү формасыннан алдагы хисап чорында өземтә;

б) медицина оешмасының конкурста катнашучы белгечкә ихтыяҗы булу турында, әлеге вазыйфа буенча бер елдан артык вакансия булуга яки медицина оешмасында яңа бүлек (хезмәт) булдыруга бәйле рәвештә, медицина оешмасының комплектлылыгын исәпкә алып мәгълүматы.»;

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Гражданинның конкурста катнашу хокукын танудан баш тарту өчен нигез булып торалар:

а) гражданинның әлеге Тәртипнең 3 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

б) әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау яки тулысынча тапшырмау.

Әлеге Тәртипнең 5 пунктында каралган документлар конкурс комиссиясе утырышында каралуга гражданны әлеге пунктта билгеләнгән конкурста катнашу хокукын танудан баш тарту өчен нигезләр булмаганда кабул ителә.»;

түбәндәге эчтәлекле 9[1] пункт өстәргә:

«91. Конкурс комиссиясе составына Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, «Татарстан Республикасы Президенты

каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциячел булмаган оешма, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау хезмәткәрләре һөнәри берлегенең Татарстан республика оешмасы, «Татарстан Республикасы медицина хезмәткәрләре ассоциациясе" коммерциячел булмаган партнерлыгы вәкилләре керә (килешү буенча).

Конкурс комиссиясе Конкурс комиссиясе рәисе, Конкурс комиссиясе рәисе урынбасары, Конкурс комиссиясенең җаваплы секретаре һәм Конкурс комиссиясе әгъзалары составында формалаша. Конкурс комиссиясе составы Министрлык боерыгы белән раслана.

Конкурс комиссиясенең рәисе - Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры, Конкурс комиссиясе рәисе урынбасары – Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры урынбасарларының берсе. Конкурс комиссиясенең җаваплы секретаре итеп Министрлык вәкиле билгеләнә.»;

түбәндәге эчтәлекле $9^2$ пункт өстәргә:

«$9^2$. Конкурс комиссиясе әлеге Тәртипнең 5 пункты нигезендә гражданин тарафыннан тапшырылган документларны карап тикшерә, медицина оешмаларының комплектлылыгын исәпкә алып, конкурста катнашучы табиб-белгечләргә булган ихтыяҗын бәяли һәм әлеге Тәртипнең 5 пунктында каралган документлар кабул ителгән көннән алып 30 көн эчендә үз карарын Конкурс комиссиясе утырышында карап тикшерүгә чыгара.

Конкурс комиссиясе грант алу өчен конкурс җиңүчесе дип табиб-белгечне тану яки танудан баш тарту турында карар кабул итә.

Табиб-белгечне грант алу өчен конкурс җиңүчесе дип танудан баш тарту өчен нигез булып торалар:

табиб-белгеч биргән документларда булган мәгълүматның дөрес булмавы;

медицина оешмасының комплектлылыгын исәпкә алып, конкурста катнашучы табиб-белгечкә булган ихтыяҗы булмау.

Конкурс комиссиясе утырышы анда конкурс комиссиясе составының кимендә өчтән икесе катнашуында хокуклы дип санала.

Конкурс комиссиясе карары (алга таба - Карар) ачык тавыш бирү юлы белән Конкурс комиссиясе утырышында катнашучы гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда хәлиткеч тавыш хокукы Конкурс комиссиясе рәисе яисә Конкурс комиссиясе рәисе урынбасарына бирелә (Конкурс комиссиясе рәисе булмаганда). Карар Конкурс комиссиясе утырышын уздыру көнендә грант алуга конкурста җиңүчеләр дип танылган табиб-белгечләр исемлеген раслау турында беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа Конкурс комиссиясе рәисе яисә аның урынбасары (Конкурс комиссиясе рәисе булмаган килеш) һәм Конкурс комиссиясенең җаваплы секретаре кул куя.

Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат Министрлык тарафыннан конкурста катнашкан медицина оешмалары җитәкчеләре һәм табиб-белгечләр игътибарына Карар кабул ителгән көннән биш көн эчендә җиткерелә.

Конкурста катнашу өчен табиб-белгечләр биргән документлар билгеләнгән тәртиптә сакланырга тиеш, аларны Министрлыкка тапшырганнан соң биш ел дәвамында табиб-белгечнең язма гаризасы буенча кире кайтарылырга мөмкин.»;

10 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Конкурс комиссиясе карары уңай буганда табиб-белгечләр, медицина оешмалары һәм Министрлык арасында Конкурс комиссиясенең уңай карары кабул ителгән көннән 14 көн эчендә грант бирү турында килешү төзелә.»;

әлеге карар белән расланган 2018 елның IV кварталында һәм 2019 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән клиника-лаборатория диагностикасы табиб-белгечләренә, табибларына Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары бирү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү тәртибендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2018 елның III – IV кварталларында һәм 2019 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән табиб-белгечләренә, клиника-лаборатория диагностикасы табибларына, фельдшерлык-акушерлык пунктлары мөдирләренә – фельдшерларына, шулай ук фельдшерлык-акушерлык пунктлары патронаж фельдшерларына, акушерларына, шәфкать туташларына 2019 елда Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары бирү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү тәртибе»;

1 пунктта «2018 елның IV кварталында һәм 2019 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән» сүзләрен «, 2018 елның III – IV кварталларында һәм 2019 елда Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларына эшкә кабул ителгән фельдшерлык-акушерлык пунктлары мөдирләренә – фельдшерларына, шулай ук фельдшерлык-акушерлык пунктлары патронаж фельдшерларына, акушерларына, шәфкать туташларына» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин